**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2021 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премияләрен бирү турында**

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен караганнан соң **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премияләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) Гайнетдинов Азат Галимҗан улына – «Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директорына;

2) Түбәндәге составтагы гражданнар төркеменә: Коноплев Александр Юрьевичка – Татарстан Республикасының «Ватан» берләшмәсе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы Советы рәисенә, Прокофьев Илья Геннадьевичка – Татарстан Республикасының «Ватан» берләшмәсе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасының эшләр идарәчесенә, Сәлахиев Рафикъ Рәшит улына – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты әйдәүче фәнни хезмәткәренә;

3) Мишина Любовь Николаевнага – «Россия пенсионерлар берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе Идарәсе рәисенә;

4) «Балаларда – көч» сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга ярдәм итү хәйрия фондына;

5) «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе каршындагы Татарстан халыклары Яшьләр ассамблеясе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасына;

6) Татарстан Республикасы буенча инвалидларның «Закал» төбәк иҗтимагый оешмасына;

7) «Умай» Идел буе гаилә академиясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасына;

8) «Сәләт» Татарстан республика яшьләр иҗтимагый фондына.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ *

Казан, Кремль
2021 ел, 02 ноябрь
№ ПУ-840